# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы**
**законнары мониторингы турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Татарстан Республикасы законнары мониторингы төшенчәсе**

Әлеге Законда Татарстан Республикасы законнары мониторингы дигәндә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматны җыю, анализлау, берләштерү һәм бәяләү буенча эшчәнлек дип аңларга кирәк.

2 статья. **Татарстан Республикасы законнары мониторингының максатлары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасы законнары мониторингы кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылык һәм хокук тәртибе режимын ныгыту, Татарстан Республикасы законнарының гамәлдә булу нәтиҗәлелеген билгеләү максатларында уздырыла.

2. Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздыру бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү;

2) Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру практикасының хокукый җайга салуның планлаштырыла торган нәтиҗәсенә туры килүен анализлау һәм бәяләү;

3) хокукый җайга салудагы каршылыкларны, кабатлауларны һәм җитешсезлекләрне, хокук кулланучылар тарафыннан төрле мәгънәдә аңлашыла

торган нормаларны, коррупция чагылышы өчен шартлар тудыруга мөмкинлек бирә торган нигезләмәләрне ачыклау;

4) закон чыгару эшчәнлегенең перспектив юнәлешләрен булдыру;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм хокук кулланучылар арасында даими элемтәләр булдыру;

6) Россия Федерациясе субъектлары карамагындагы эшләргә һәм Россия Федерациясе белән Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы эшләргә кертелгән мәсьәләләрнең җайга салынышы дәрәҗәсен билгеләү.

3 статья. **Татарстан Республикасы законнары мониторингы принциплары**

Татарстан Республикасы законнары мониторингы принциплары түбәндәгеләр:

1) өзексезлек;

2) системалылык;

3) комплекслылык;

4) планлылык;

5) максатчанлык;

6) хәбәрдарлык.

4 статья. **Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздыру турында карар кабул итү**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары үз карамакларындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы законнары мониторингын ел саен үзләре раслый торган планнар нигезендә өзексез рәвештә гамәлгә ашыралар.

2. Татарстан Республикасы законнары мониторингы шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты (комитетлары) тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яисә аның Президиумы кушуы буенча гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган тәртиптә Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздыру турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы яисә аның Президиумы карары белән рәсмиләштерелә, анда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) үз карамагындагы эшләр буенча Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты (алга таба – комитет);

2) мониторинг объекты (Татарстан Республикасы законын йә аның аерым структур өлешен, шул исәптән Татарстан Республикасының аерым территориясендә һәм (яисә) аерым вакыт аралыгында, гамәлгә ашыру; иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең аерым өлкәсен җайга сала торган Татарстан Республикасы законнары комплексын гамәлгә ашыру);

3) мониторинг уздыру срогы.

4. Татарстан Республикасы законнарын аларның федераль законнарга туры килүен тәэмин итү буенча мониторинглау Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздырганда комитетның вәкаләтләре**

1. Комитет федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның барышы турында таләпләр җибәрә ала.

2. Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздыру тиешле мәсьәләне тикшерүгә юнәлдерелгән парламент тыңлаулары, киңәшмәләр, конференцияләр, семинарлар һәм бүтән чаралар уздыру юлы белән башкарылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы законнарын һәрьяклап һәм тулы мониторинглауны тәэмин итү өчен комитет Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар вәкилләреннән, галимнәрдән һәм белгечләрдән эшче төркемнәр төзергә мөмкин.

6 статья. **Татарстан Республикасы законнары мониторингының стадияләре**

Татарстан Республикасы законнары мониторингына түбәндәге стадияләр керә:

1) Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү;

2) Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү белешмәләрен анализлау;

3) Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм аны арттыру чараларын эшләү.

7 статья. **Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү**

1. Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү барышында комитет түбәндәгеләрне ачыклый торган мәгълүматны җыя, анализлый һәм берләштерә:

1) Татарстан Республикасы законнарының максатларын (бурычларын) һәм хокукый җайга салу предметын;

2) тиешле иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу торышының гомуми характеристикасын (тиешле иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеген, күрсәтелгән норматив хокукый актлар системасында тикшерелә торган Татарстан Республикасы законнарының урынын, тикшерелә торган Татарстан Республикасы законнары нигезендә кабул итү мәҗбүри булган тиешле норматив хокукый актларның булуын);

3) Татарстан Республикасы законнарының гамәли көче кагыла торган затлар даирәсен, аларның хокукларын һәм бурычларын;

4) Татарстан Республикасы законнарын халыкка җиткерү тәртибен (рәсми бастырып чыгару датасын һәм чыганагын, үз көченә керү датасын);

5) Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылыкны, тикшерелә торган хокук мөнәсәбәтләре субъектларына карата хокукый йогынтының бүтән чараларын һәм аларны куллану практикасын.

2. Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

1) дәүләт хакимияте вәкаләтле органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, аларның структур бүлекчәләренең һәм вазыйфаи затларының хокук куллану практикасы турында мәгълүматы;

2) гражданнардан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына керә һәм тикшерелә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге турында мәгълүмат;

3) Татарстан Республикасы законнарына суд тәртибендә дәгъва белдерү турында, кабул ителгән карарлар (карарнамәләр) һәм аларны үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

4) Татарстан Республикасы законнарына карата прокурор мөнәсәбәтенең кабул ителгән чаралары турында мәгълүмат (протестлар һәм күрсәтмәләр, судка гаризалар);

5) дәүләт хакимиятенең башка органнарының, шул исәптән кабул ителә торган норматив хокукый актларның Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм гамәлдәге законнарга туры килүкилмәвен тикшереп торучы органнарның бәяләмәләре турында мәгълүмат;

6) суд практикасы, прокурор статистикасы турында мәгълүмат, хокук саклау органнарының Татарстан Республикасы законнарын куллануга кагылышлы бүтән белешмәләре;

7) рәсми шәрехләү актлары;

8) социологик тикшеренүләрнең: гражданнардан, белгечләрдән анкеталар тутыртуның; җәмәгатьчелек фикерен башкача белешүнең; белгечләргә тестлар һәм тренинглар уздыруның күрсәткечләре;

9) эксперт бәяләмәләре, галимнәрнең, белгечләрнең фикерләре;

10) фәнни-практик конференцияләрнең, фәнни-практик семинарларның резолюцияләре, парламент тыңлауларының һәм "түгәрәк өстәлләрнең" тәкъдимнәре;

11) күчмә утырышларның һәм киңәшмәләрнең йомгаклары;

12) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләрен үтәү турында мәгълүмат, депутат таләпләренә җаваплар, депутат тикшерүләре нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр.

8 статья. **Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү күрсәткечләрен анализлау**

1. Комитет Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү күрсәткечләрен анализлый, аның барышында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның түбәндәге күрсәткечләре тикшерелергә мөмкин:

1) социаль-психологик:

а) җайга салына торган иҗтимагый мөнәсәбәтләр субъектларының Татарстан Республикасы законнарының гамәли көче һәм асылы турында мәгълүматлы булуы;

б) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның объектив зарурлыгын һәм социаль әһәмиятлелеген бәяләү;

в) хокукый мөнәсәбәтләр субъектлары мотивациясенең Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә йогынтысы;

2) хокукый:

а) хокук куллану практикасының Татарстан Республикасы Законы таләпләренә һәм (яисә) аны үстерү өчен кабул ителгән Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актына туры килүе;

б) Татарстан Республикасы законында билгеләнгән юридик процедураларны үтәү;

в) тикшерелә торган Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хокукый актларның булуы; аларны үтәү мәсьәләләре буенча кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының һәм муниципаль норматив хокукый актларның ярашучанлыгы;

г) дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан компетенцияне үзләштерү дәрәҗәсе;

д) хокукый җайга салуда җитешсезлекләр булу: юридик коллизияләр, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны кабатлау, Татарстан Республикасы законнарында кирәкле юридик нормаларның булмавы, гамәлгә яраксыз нормалар булу;

3) оештыру-идарәчел:

а) Татарстан Республикасы законнарын куллану мәсьәләләре буенча фәнни-практик комментарийлар һәм методик рекомендацияләр, аңлатулар булу;

б) Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өчен матди нигез булу (аны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән финанс ресурслары күләме);

в) хокук кулланучыларның квалификация дәрәҗәсе, кадрлар белән тәэмин ителеш;

г) Татарстан Республикасы законнарын хокук кулланучылар тарафыннан үтәү дәрәҗәсе.

2. Тикшерелергә тиешле күрсәткечләрнең исемлеге комитет тарафыннан билгеләнә.

3. Анализ нәтиҗәләре буенча комитет Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүмат әзерли, анда Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны күзәтү предметы һәм нигезе, Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру күрсәткечләре, гомумиләштерүче йомгаклар ачыклана.

9 статья. **Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү**

1. Комитет Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген билгели.

2. Нәтиҗәлелекне бәяләүнең төп критерийлары түбәндәгеләр була:

1) Татарстан Республикасы законнарының актуальлелеге;

2) Татарстан Республикасы законнарының гамәлдәге законнарга туры килүе;

3) нормаларны үтәүнең реаль булуы, шул исәптән аларның финанс белән тәэмин ителеше;

4) Татарстан Республикасы законнарын кабул итүнең нәтиҗәлелеге (социаль-икътисадый нәтиҗә, җайга салына торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге үзгәрешләр, нормативлар белән билгеләнгән максатларга ирешү).

3. Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү йомгаклары буенча комитет мониторинг йомгаклары турында карар кабул итә, анда, кирәк булганда, комитетның Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча рекомендацияләре күрсәтелә.

4. Татарстан Республикасы законнары мониторингының йомгаклары турында кабул ителгән карарны исәпкә алып, комитет түбәндәгеләрне әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында һәм (яисә) Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында Татарстан Республикасы законы проектын;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын, анда түбәндәге тәкъдимнәр һәм (яисә) рекомендацияләр чагылдырыла:

а) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына федераль закон проектын кертү турында;

б) мониторинг барышында ачыкланган мәсьәләләр буенча федераль дәүләт хакимияте органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында;

в) Татарстан Республикасы законнарында каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын (хокукый актларын) һәм муниципаль норматив хокукый актларны эшләү һәм кабул итү турында;

г) Татарстан Республикасының максатчан программаларын әзерләү турында йә гамәлдәге программаларга үзгәрешләр кертү турында;

д) мониторинг барышында ачыкланган Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү турында;

е) Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән аңлату һәм мәгълүмат чараларын уздыру турында;

ж) Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән, мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка тәкъдимнәр.

10 статья. **Татарстан Республикасы законнарының торышы турында нотык**

1. Татарстан Республикасы законнарының торышы турындагы нотык Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан закон чыгару эшчәнлегенә йомгаклар ясау рәвеше булып тора, һәм ул дәүләт хакимияте органнарын, җирле үзидарә органнарын һәм Татарстан Республикасы халкын кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары турында, законнар белән җайга салуның

актуаль проблемалары турында һәм Татарстан Республикасы законнарын алга таба үстерү турында системалаштырылган мәгълүмат белән тәэмин итү максатларында әзерләнә.

2. Татарстан Республикасы законнарының торышы турындагы нотыкны оештыру өчен нигез буларак Татарстан Республикасы законнары мониторингының нәтиҗәләре кулланыла.

3. Татарстан Республикасы законнарының торышы турындагы нотыкны әзерләү тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән раслана.

11 статья. **Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алып бару**

1. Күрсәткечләре Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздырганда файдаланыла торган Татарстан Республикасы законнары исәпкә алып барылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алып барганда һәр Татарстан Республикасы законы буенча мәгълүмат системалаштырыла һәм Татарстан Республикасы законы паспорты рәвешендә рәсмиләштерелә, анда түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) белешмә мәгълүмат (законның исеме, реквизитлары, законның үз көченә керү датасы, рәсми басылып чыгу чыганагы, законның гамәлдә булу срогы);

2) законга кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр (тиешле законнарның исеме, реквизитлары, рәсми басылып чыгу чыганагы, аларның үз көченә керү датасы һәм гамәлдә булу срогы);

3) Татарстан Республикасы законына карата суд карарларының, прокурор мөнәсәбәте һәм юстиция органнары актларының исемлеге, шулай ук аны карау йомгаклары буенча кабул ителгән Дәүләт Советы карарлары (булса).

3. Татарстан Республикасы законнары паспорты Интернет челтәрендә Дәүләт Советының рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 3 июле
№ 49-ТРЗ